ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2023 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады хакында

2023 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына «Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү», «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү», «Татарстан Республикасын фәнни-технологик үстерү» дәүләт программаларын, мәгариф өлкәсендә федераль программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруны дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына 2023 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладында булган тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына мәгариф өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2563-VI ДС